**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.:+7 (84365) 2-30-50, факс: (84365) 2-30-50,, e-mail: biektau@tatar.ru, www./vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР**
**6 декабрь 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 341**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләти (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе вазыйфаларын башкаручы Павлов Иван Александр улын, гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы буенча федераль салым инспекциясенең районара инспекциясендә “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә дәүләт теркәве буенча гариза бирүче буларак чыгыш ясарга вәкаләтләргә.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының хокукый хәлен камилләштерү турында”, 2016 елның 8 июнендәге 64 номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының хокукый хәлен камилләштерү турында”, 2016 елның 8 июнендәге 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”, 2018 елның 28 мартындагы 214 номерлы карарын.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр

челтәрендә Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

Кушымта

Расланган
ТР Биектау муниципаль районы
Советы карары белән
«06» декабрь 2019 № 341

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ “МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ” МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Палата) – тулы исеме, “ТР Биектау муниципаль районы МҖМП” МКУ – кыскартылган исеме, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм Биектау муниципаль районы (алга таба – муниципаль район) норматив хокукый актлары нигезендә булдырылган.

1.2. Палата гамәлдә булган законнар һәм муниципаль районның норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль районның муниципаль милке белән, шулай ук муниципаль район карамагында яки милкендә булган җир кишәрлекләре белән идарә итү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыра һәм муниципаль районның җирле үзидарәсенең даими эшләүче органы булып тора.

1.3. Палата үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашырганда Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – район Башкарма комитеты), муниципаль районның билгеле җирле үзидарә органнары структур бүлекчәләре, дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итә.

1.4. Палата Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты алдында хисап тота.

1.5. Палата үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республиаксы законнары, “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль районның норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә белән эш йөртә.

1.6. Палата тарафыннан әзерләнгән карарлар аның Җитәкчесенең карарлары, әмерләре рәвешендә рәсмиләштерелә.

1.7. Палата муниципаль казна учреждениесе формасында юридик зат булып тора, үз балансы, банк учреждениеләрендә хисап һәм башка счетлары, мөһере, муниципаль район гербы һәм үз исеме булган бланклары бар.

1.8. Палата үз исеменнән башка юридик һәм физик затлар белән хокукый мөнәсәбәтләргә керергә мөмкин.

1.9. Палатаның структурасы муниципаль районның җирле үзидарә башкарма органнары хезмәткәрләренең эшчәнлеге өчен түләү фонды һәм күләме чигендә район Советы тарафыннан раслана.

1.10. Палата муниципаль район җирлегендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм дәүләт объектларына кагылышлы Биектау райны Администрациясе 2006 елның 1 нче гыйнварына кадәр кабул иткән килешүләр һәм карарлар буенча Биектау районы Администрациясенең хокуклы варисы булып тора.

1.11. Палатаның урнашкан урыны: 422701, Татарстан Республикасы, Биектау авылы, Полковая урамы, 9 нчы йорт.

## 2. Палатаның бурычлары

Палатаның төп бурычлары булып тора:

2.1. Муниципаль милекне тоту, куллану һәм эш итүне билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыру, шул исәптән муниципаль милектә булган җир ресурслары һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир ресурслары белән.

2.2. Муниципаль милек һәм җир ресурсларын кулланудан максималь нәтиҗәне һәм керемне тәэмин итү.

2.3. Күчемле һәм күчемсез муниципаль милекне куллануны контрольдә тотуны тәэмин итү.

## 3. Палатаның төп функцияләре

Палата төп бурычларны чишү кысаларында, үз компетенцияләре кысаларында түбәндәге функцияләрне тормышка ашыра:

3.1. Муниципаль районның норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль милекне арендага бирү, аны залогка, ышанычлы идарәгә, түләүсез вакыты чикләнгән куллануга бирү турында карарлар кабул итә.

3.2. Законнар белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль милектә булган муниципаль милек һәм җир кишәрлекләренең, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең сатучысы функцияләрен башкара. Сатулар (конкурслар, аукционнар) уздыру турында махсуслаштырылган оешмалар белән шартнамәләр төзи.

Билгеләнгән тәртиптә сату өчен хосусыйлаштыру объектларын махсуслаштырылган оешмаларга тапшыра.

3.3. Муниципаль милек Реестрын һәм муниципаль җирләр Реестрын алып бара, муниципаль милек исәбе, җир кишәрлекләре системасы, эшчәнлеген, муниципаль милек белән кулланунның булуы һәм куллану турында мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итә.

3.4. Муниципаль милекне тапшыруны тормышка ашыра, шул исәптән җир кишәрлекләрен федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, башка муницапаль бермәлекләр милкенә һәм башка милек формаларын тапшыруны тормышка ашыра.

3.5. Җир кишәрлекләрен муниципаль һәм дәүләт учреждениеләренә, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хакимияте органнарына даими

(вакыты чикләнмәгән) куллануга бирү хокукында, муниципаль унитар предприятиеләргә арендага бирүне тормышка ашыра.

3.6. Карарлар кабул итә:

- җир кишәрлекләрен арендага яки милеккә тапшыру турында;

- муниципаль милек белән идарә итүгә;

- муниципаль акцияләр пакетларын, өлешләрне тормышка ашыру, аларны залогка, ышанычлы идарә итүгә тапшыру;

- торак пункт җирләреннән ирекле җир кишәрлекләре белән, Татарстан Республикасы резерв фонды составына кертелгән, шул исәптән шәхси торак төзелешен тормышка ашыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен очраклардан кала.

3.7. Законнар нигезендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре җирләреннән җир кишәрлекләрен сату турында милекчеләргә хәбәрнамәләрне карый һәм җир кишәрлекләрен муниципаль милеккә сатып алу турында, шулай ук аларны сатып алудан баш тарту турында карар кабул итә.

3.8. Башкарма комитет карарлары нигезендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләрен ала.

3.9. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Законнары белән күздә тотылган очракларда һәм тәртиптә, билгеле гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

3.10. Муниципаль җир контролен тормышка ашыра.

3.11. Үз компетенциясе чикләрендә муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлелкәре белән идарә итү белән бәйле эшләрнең заказчысы һәм җир реформасын уздыручы буларак чыгыш ясый, аларны тормышка ашыруга заказларны конкурс нигезендә урнаштыра.

3.12. Законнар белән билгеләнгән тәртиптә, район Советы карарлары нигезендә оештырыла торган муниципаль унитар предприятиеләрнең учредителе буларак чыгыш ясый.

3.13. Муниципаль унитар предприятиеләргә алар тарафыннан устав бурычларын башкару өчен кирәкле милекнең оптималь күләмен билгели.

Муниципаль милектә булган милекне, шул исәптән социаль-мәдәният өлкәсе объектларын муниципаль унитар предприятиеләрнең хуҗалык итүенә беркетә.

3.14. Муниципаль унитар предприятиеләргә билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә ризалык бирә:

- күчемсез милек белән башкача идарә итү һәм читләштерү, шул исәптән залогка, арендага, милек кертемнәрен оешмаларның устав (склад) капиталына (фондына) кертү, шулай ук федераль законнар, башка норматив хокукый актлар яки оешма уставында күздә тотылган очракларда башка килешүләр төзү.

- эре сату-алулар һәм кызыксынулар булган башка сату-алуларны тормышка ашыру;

- займнар, поручительлек бирү белән, банк гарантияләрен алу, башка төр җаваплылык, бурычны кичектереп тору, бурычны күчерү белән бәйле сату-алуларны тормышка ашыру, шулай ук гади ширкәтләр шартнамәсен төзү;

- предприятиенең башка юридик затларда катнашуы;

- филиаллар булдыру һәм вәкиллекләр ачу.

Муниципаль унитар предприятиеләргә бурычка алып торулар күләмен һәм җәлеп ителгән чараларның куллану юнәлешен килештерә.

3.15. Муниципаль милектә булган милекне билгеләнгән тәртиптә муниципаль учежденииеләргә оператив идарә итү хокукында беркетә, шулай ук билгеләнгән тәртиптә оператив идарә итү хокукында беркетелгән артык, кулланылмаган яки урынлы кулланылмаган милекне алуны тормышка ашыра.

3.16. Муниципаль унитар предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә, билгеләнгән тәртиптә башка затларга хуҗалык итү карамагына һәм оператив идарә итүгә беркетелгән җир кишәрлекләрен һәм башка муниципаль милекне билгеләнеше буенча идарә итү, тоту, гамәл кылу, куллану һәм сакланышын контрольдә тотуны тормышка ашыра һәм кагыйдә бозулар ачыкланган очракта, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, аларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чараларны күрә.

3.17. Үз компетенциясе кысаларында муниципаль милек объектлары инвентаризациясен, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә нәтиҗәле куллану мәсьәләләре һәм муниципаль милек һәм җир кишәрлекләре сакланышы буенча документаль һәм башка тикшерүләр билгели һәм уздыра.

3.18. Төп фондны, шулай ук хуҗалык, муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль унитар предприятиеләрдә оператив идарә итү карамагында булган тукталган яки (һәм) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына тотылган чыгымнарны сызып ташлауны тормышка ашыра һәм контрольдә тота.

3.19. Муниципаль унитар предприятиеләргә карата карарлар кабел итә, шул исәптән үзгәртеп кору, бетерү турында. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары кысаларында, муниципаль районның устав капиталындагы өлеше белән акционер җәмгыятьләрнең төпсезлеге турында гамәлне башкаруны һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итә.

Федераль законнар нигезендә муниципаль унитар предприятиеләрне, устав капиталларында муниципаль район өлеше белән акционер җәмгыятьләрне судтан тыш бетерү процедураларын федераль законнар нигезендә тормышка ашыра, аларны уздыруны контрольдә тота.

3.20. Муниципаль унитар предприятиеләрне, муниципаль районның устав капиталындагы өлеше белән акционер җәмгыятьләрне бөлгенлеккә төшермәү (банкротлыкка) чыгармау, кризиска каршы тору белән идарә итү чараларны эшләп чыгаруда һәм тормышка ашыруда катнаша.

3.21. Башкарма комитет карары нигезендә билгеле елга муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы) проектын эшләп чыгара.

3.22. Муниципаль унитар предприятиеләр һәм башка хосусыйлаштыру объектларын әзреләү буенча чараларны тормышка ашыра.

Хосусыйлаштырыла торган милеккә бәя бирүне уздыруны тормышка ашыра, бәясен раслый һәм хосусыйлаштырыла торган предприятиеләрнең устав капиталлары күләмен билгели.

3.23. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру фараз планына (программага) яраклаштырып муниципаль милекне (акцияләр, өлешләр, пайлар, оешмаларның милек комплекслары) хосусыйлаштыру турында, шул исәптән кертем сыйфатында хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларына кертү турында карарлар кабул итә.

3.24. Массакүләм мәгълүмат чараларында муниципаль милекне хосусыйлаштыру, шулай ук хосусыйлаштыру белән сату-алулар нәтиҗәләре турында мәгълүматлар бастыруны тәэмин итә.

3.25. Законнар нигезендә муниципаль район исеменнән акцияләре муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре (хуҗалык җәмгыятьләре) акционеры (катнашучысы) хокукларын тормышка ашыра.

3.26. Башкарма комитетка, район Советына һәм Татарстан Республикасының вәкаләтле органына җир һәм милек мөнәсәбәтләре буенча билгеләнгән тәртиптә, узган елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында хисап әзерли һәм тәкъдим итә.

3.27. Үз компетенциясе кысаларында муниципаль районның идарә һәм контроль органнарына һәм устав капиталларында муниципаль район өлеше белән хуҗалык җәмгыятьләренә вәкилләргә кандидатларны акционерларның гомуми җыелышында сайлану өчен алга чыгара. Аларны укытуны, җитәкчелек итүне, методик тәэмин итүне һәм алырның эшчәнлеген контрольдә тотуны оештыра.

3.28. Билгеләнгән тәртиптә муниципаль район вәкилләренә хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарында карар проектларын һәм аларга тавыш бирүне законнар белән күздә тотылган тәртиптә килештерә.

Муниципаль район вәкилләре тарафыннан, хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча тавыш бирүдә позицияләрен килештерү буенча йөкләмәләрен башкаругы контрольдә тота.

3.29. Муниципаль районда торак сәясәтен эшләп чыгаруда һәм тормышка ашыруда, торак фондының күчемсез милке белән идарә итү системасын булдыруда катнаша, шул исәптән муниципаль милектә булган төзелеп бетмәгән төзелеш һәм күпфатирлы йортларда торак биналар объектлары да.

Гражданнарга социаль найм шартнамәләре буенча бирелгән күпфатирлы йортларның торак биналарында муниципаль хисап системасын оештыра һәм алар белән идарә итү механизмнарын эшләп чыгара.

Торак милекчәләре ширкәтләрен булдыру һәм эшчәнлеге өчен уңай шартлар булдыруга ярдәм итә.

Муниципаль милектә булган торак фонды объектларын хуҗалык итүгә, оператив идарә итүгә, түләүсез куллануга һәм башка махсуслаштырылган һәм идарә оешмаларына идарә итүгә тапшыра.

3.30. Муниципаль торак фондын хосусыйлаштыруны тормышка ашыра.

3.31. Хосусыйлаштырудан, муниципаль милекне кулланудан акчалар керү турында, шул исәптән җир кишәрлекләреннән дә фараз мәгълүматларын билгеләнгән тәртиптә эшләп чыгара һәм билгеле җирле үзидарә органнарына тапшыра.

3.32. Дивидентларның оптималь күләмен билгели, муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләрнең акцияләре (башка хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларындагы өлешләре буенча керемнәр) буенча дивидендларның җирле бюджетка күчерүе буенча чаралар кабул итә һәм контрольне тормышка ашыра.

3.33. Муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста кеременең бер өлешен җирле бюджетка күчерүне оештыра.

Сатудан һәм арендадан җирле бюджетка акчалар керүне контрольдә тотуны, шулай ук муниципаль милек белән башка куллануны, шул исәптән муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен куллануны контрольдә тотуны тормышка ашыра.

3.34. Муниципаль милек, шул исәптән җир кишәрлекләрен куллануга аренда түләве күләмен билгеләү буенча район Советына тәкъдимнәр эшләп чыгара һәм тәкъдим итә.

3.35. Муниципаль унитар предпритиеләр җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләрен билгеләнгән тәртиптә төзи, үзгәртә һәм туктата.

3.36. Муниципаль район исеменнән үз компетенциясе чикләрендә, муниципаль милеккә карата муниципаль берәмлекнең милек хокукларын саклауны тәэмин итә.

3.37. Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында мәсьәләләрне чишкән вакытта, шул исәптән бөлгенлеккә төшү (банкротлык) процедураларының инициаторы булган очракта, шулай ук банкротлык турында эшләрдә һәм банкротлык процедуралары вакытында, муниципаль, устав (склад) капиталларында муниципаль берәмлек өлеше (кертеме) булган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләренең милек иясе буларак районның законлы мәнфәгатьләрен тәкъдим итә.

3.38. Дәүләт милке һәм муниципаль районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган җир кишәрлекләре белән идарә итү өлкәсендә, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыра.

3.39. Палатага йөкләнгән вәкаләтләр чикләрендә башка функцияләрне башкара.

## 4. Палатаның хокуклары һәм йөкләмәләре

4. 1. Палата хокуклы:

4.1.1. Үз исеменнән килешүләр төзергә, законнар белән билгеләнгән тәртиптә милек һәм милки булмаган хокукларны алырга, йөкләмәләр йөртергә, судта дәгъвачы һәм җавап бирүче булырга.

4.1.2. Устав капиталларында муниципаль берәмлек өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренең акционерлар җыелышына һәм акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына көн тәртибенә тәкъдимнәр җибәрергә, аларны уздыруны контрольдә тотырга.

4.1.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль учреждениеләрдән, җирле үзидарә органнарыннан, Район территориясендә урнашкан башка оешмалардан, Палатага йөкләнгән бурычларны башкару өчен кирәкле законнар тарафыннан күздә

тотылган икътисади, статистик, хокукый һәм башка мәгълүматны түләүсез нигездә алырга.

4.1.4. Законнар белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль район территориясендә урнашкан Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсеннән түләүсез нигездә җир кишәрлегенә һәм күчемсез милек объектларына һәм алар белән сату-алуларга хокуклар турында мәгълүматлар, муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре белән идарә итү, муниципаль милек исәбен һәм аның реестрын алып бару өчен кирәкле башка мәгълүматларны соратырга һәм алырга.

4.1.5. Судка Район исеменнән, хосусыйлаштыру, муниципаль милек белән идарә итү һәм гамәл кылу буенча Районны яклап дәгъвалар (гаризалар) белән мөрәҗәгать итәргә, шул исәптән түбәндәгеләр буенча:

муниципаль милекне хосусыйлаштыру, аның белән идарә итү килешүләрен көчсез дип табу;

муниципаль унитар предприятиеләр керемнең бер өлешен түләтү;

муниципаль милекне, шул исәптән җир кишәрлекләрен куллану өчен аренда һәм башка түләүләр түләтү;

физик һәм юридик затларның нигезсез эшләре белән муниципаль оешмага китергән зыяннарын каплату;

законнар белән күздә тотылган башка мәсьәләләр буенча.

4.1.6. Законнар белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә хуҗалык алып бару хокукында, оператив, ышанычлы идарә итүче оешмаларга беркетелгән муниципаль милекне тартып алырга.

4.1.7. Дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгать итәргә:

муниципаль районның җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары проектларын эшләп чыгарганда түләүсез методик һәм практик ярдәм алу мәсьәләләре, методик материаллар, җир һәм милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә инструкцияләр алу буенча;

Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган объектларны муниципаль районы милкенә тапшыру буенча тәкъдимнәр белән.

4.2. Палата бурычлы:

4.2.1. Үзенең компетенцияләре кысаларында муниципаль районның икътисади мәнфәгатьләренә зыян китерүне булдырмыйча җир ресурслары һәм муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итәргә.

4.2.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштырган вакытта закон бозылган очракларда, суд тәртибендә муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы килешүне өзү, законнар һәм муниципаль милекне һәм җир ресурсларын сату-алу шартнамәләре нигезендә зыянны капларга һәм башка чаралар куллану турында дәгъва белдерергә;

4.2.3. Гаеплеләрне җавапка тарту турында карар кабул итү өчен, билгеләнгән тәртиптә хокук саклау органнарына муниципаль милекне тоту, куллану һәм гамәл кылу өлкәсендә закон бозылган очраклар турында, җир мөнәсәбәтләре белән бәйле мәсьәләләр буенча материалларны җибәрергә.

4.2.4. Законнар белән билгеләнгән тәртиптә район Советына, Башкарма комитетка, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына үз

эшчәнлекләре турында хисаплар һәм мәгълүматлар җибәрергә.

## 5. Палата эшчәнлеген оештыру

5.1. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе район Советы тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

5.2. Палата рәисе муниципаль районның җирле үзидарә органы вазыйфаи заты булып тора.

5.2. Палата рәисе:

Үз вәкаләтләре кысаларында Палата исеменнән карарлар чыгара.

Палата рәисенең хокукый актлары район территориясендә, район территориясендә урнашкан барлык предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый һәм дини оешмалар, шулай ук гражданнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан башкару өчен мәҗбүри.

ышанычнамәдән башка Палата исеменнән гамәл кыла, аның мәнфәгатьләрен барлык учреждениеләрдә һәм оешмаларда, судларда тәкъдим итә, Палата хезмәткәрләре мәҗбүри рәвештә үтәргә тиешле боерыклар, крарарлар чыгара, эчке документларны раслый;

Палата исеменнән шартнамәләр, контрактлар, килешүләр һәм башка сату-алуларны төзи, аларны башкаруны тәэмин итә;

банкларда хисап счёты һәм башка счётлар ача һәм яба, алар буенча эш йөртә, финанс документларына кул куя;

район Советы раславына хезмәт хакы фонды кысаларында Палатаның төзелешен һәм штатлы расписаниесен тәкъдим итә;

Палатаның эшчәнлеге белән бер генә кеше идарә итә торган нигездә гомуми җитәкчелек итүне тормышка ашыра һәм вәкаләтле органга йөкләнгән функцияләрне башкару өчен шәхси җавалылык йөртә;

Палата белгечләре арасында вазыйфаларны бүлә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфа күрсәтмәләрен раслый;

гамәлдәге законнар нигезендә Палата хезмәткәрләренә мактау һәм шелтә белдерә;

үз компетенцияләре кысаларында күрсәтмәләр һәм боерыкнамәләр бирә;

Палатага тапшырылган милекне исәптә тоту һәм саклауны оештыра;

Палата хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә;

гражданнарны кабул итүне алып бара, аларның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый;

Палата функцияләренә кергән башка эшләрне башкара.

## 6. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу һәм җайга салу

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы дигәндә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе хезмәткәренең (алга таба – учреждение хезмәткәре) шәхси кызыксынганлыгы, аның тарафыннан хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә башкаруга тәэсир итәргә мөмкин булган һәм учреждение хезмәткәренең шәхси

кызыксынганлыгы һәм ул хезмәткәр булган учреждениенең законлы кызыксынулары арасында, учреждениенең милкенә һәм (яки) эшлекле репутациясенә зыян салырга мөмкин булган каршылык килеп чыга торган яки каршылык килеп чыгарга мөмкин булган хәл аңлашыла.

6.2 Учреждение хезмәткәренең аның тарафыннан хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә башкаруга тәэсир иткән яки тәэсир итәргә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы дигәндә, учреждение хезмәткәре тарафыннан үз хезмәт йөкләмәләрен башкарганда үзенә яки өченче затлар өчен акча, кыйммәтләр, башка милек, шул исәптән милек хокуклары, яки милек хокукы харатерындагы хезмәтләр алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.3 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” муниципаль казна учреждениесе рәисе (алга таба – учреждение рәисе) учредительне хезмәт йөкләмәләрен башкарганда, мәнфәгатьләр каршылыгы килеп туган яки килеп туарга мөмкин булган шәхси кызыксынганлык килеп чыгуы турында хәбәр итәргән тиеш.

6.4. Учреждение хезмәткәре учреждение рәисенә вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда, мәнфәгатьләр каршылыгы килеп туган яки килеп туарга мөмкин булган шәхси кызыксынганлык килеп чыгуы турында хәбәр итәргә тиеш. Учреждение рәисенә хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булырга тиешле мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе учреждение рәисе тарафыннан билгеләнә.

## 7. Палатаның милке һәм финанслары

7.1. Палата әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән максатларга ирешү өчен бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән акчаны һәм милекне куллана.

7.2. Палата милке аңа милек хуҗасы тарафыннан оператив идарә итү хокукында беркетелә.

7.3. Палата үзенә беркетелгән милеккә карата гамәлдәге законнар, әлеге Нигезләмә нигезендә тормышка ашыра һәм үз эшчәнлеге максатларында аның белән куллану һәм эш итү хокукына ия.

7.4. Палата үзенең йөкләмәләре буенча кулланылышта булган акча өчен җавап бирә. Алар җитмәгән очракта билгеле милекнең йөкләмәләре буенча җаваплылыкны үз өстенә ала.

7.5. Палата аңа бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән акчалар хисабына алынган үзенә беркетелгән милекне читләштерә, башка төрле ысул белән гамәл кылырга хокуклы.

7.6. Палатының милке һәм акчалары аның балансында күрсәтелә һәм гамәлдәге законнар нигезендә кулланыла.

7.7. Милек иясе артык, кулланылмый торган яисә билгеләнеше буенча кулланылмый торган милекне алырга һәм аның белән үз дигәнчә гамәл кылырга хокуклы.

7.8: Палатаның милкен һәм акчаларын формалаштыручы төп финанслау чыганаклары булып торалар:

- бюджет ассигнованиеләре;

- башка законлы кертемнәр.

7.9. Палатаның финанс-хуҗалык эшчәнлеге чыгымнарның расланган бюднетсметасы нигезендә тормышка ашырыла.

## 8. Палатаны бетерү һәм үзгәртеп кору тәртибе

8.1. Палатаны бетерү һәм үзгәртеп кору Россия Федерациясе Гражданнар кодексы белән күздә тотылган тәртиптә һәм формаларда тормышка ашырыла.

8.2. Палатаны үзгәртеп кору турында карарны Совет кабул итә.

8.3. Палатаны үзгәртеп корганда аның барлык документлары хокукый вариска тапшырыла. Документларны тапшыру, законнар белән билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

8.4. Палатаны бетерү Совет карары буенча тормышка ашырыла.

8.5. Палатаны бетерү, законнар тарафыннан билгеләнә торган бетерү комиссиясе тарафыннан тормышка ашырыла.

8.6. Бетерү комиссиясе Палатның милкенә бәя бирә, бетерү балансы төзи.

8.7. Совет (учредитель) гамәлдәге законнар нигезендә Палатаны бетерү тәртибен һәм срокларын билгели, бетерү балансын раслый.

8.8. Бетерү комиссиясен билгеләү датасыннан аңа бетерелә торган палата эшләре буенча вәкаләтләр күчә.

8.9. Палатаны бетергән вакытта кредиторларны таләпләре, Гражданнар кодексы белән билгеләнгән тәртиптә чират нигезендә канагатьләндерелә.

8.10. Кредиторларның таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган милек, бетерелгән очракта, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкенә тапшырыла.

8.11. Бетерү комиссиясе, гамәлдәге закон нормалары буенча Палатага китерелгән зыян өчен җаваплылык йөртә.

8.12. Палатаны бетерү тәмамланган дип, ә Палата – үзенең яшәвен туктаткан дип, бу хакта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кертелгәннән соң санала.

## 9. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

9.1. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе Совет карары белән тормышка ашырыла.

9.2. Әлеге Нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, закон белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узган датадан үз көченә керә.